ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 422-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кертелгән «2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 422-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 1979-VI ДС

Проект

Закон чыгару инициативасы
хокукы субъекты –
Татарстан Республикасы Рәисе

**2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында**

**Татарстан Республикасы Законы**

**1 статья**

2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 452 715 259,1 мең сум һәм чыгымнар буенча 463 181 407,9 мең сум күләмендә, чыгымнарның керемнәрдән артуын 10 466 148,8 мең сум күләмендә һәм түбәндәге күрсәткечләре белән расларга:

1) әлеге Законның 1 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

2) әлеге Законның 2 нче кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;

3) әлеге Законның 3 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;

4) әлеге Законның 4 нче кушымтасы нигезендә бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

**«2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә «2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты тәкъдим ителә.

2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында еллык хисап Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^4$ статьясының 2 пункты нигезендә тупланды.

Закон проекты Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^5$ статьясы таләпләре нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы бюджетының керемнәре, чыгымнар һәм кытлыгы күрсәтелгән закон текстыннан тора.

Түбәндәге күрсәткечләрне раслау закон проектына аерым кушымталар булып кертелә:

бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре;

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;

бюджетлар чыгымнарының бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары;

бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $97^3$ статьясының 3 пункты нигезендә 2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап тышкы тикшерү уздыру өчен билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы Хисап палатасына тапшырылды.

**«2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы кабул ителүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, гамәлдә булуы туктатып торылырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип тану, гамәлдә булуын туктатып тору, үзгәрешләр кертү турында яисә яңа Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын кабул итүне таләп итми.

**«2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«2022 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.